| | |
|---|---|
| ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 24.11.2021 | 07 |

пос. Октябрьский

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 нче елның 4 нче декабрендә 10 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Ключищи авыл җирлеге гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2021 нче елның 4 нче декабрендә 11 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Ключищи авыл җирлеге гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Халык исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла.

1 этап: Дачная ур., Үзәк ур., Завод ур.

2 этап: Волжская урамында яшәүчеләр, Колхоз урамы, Солнечная урамы

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:
- Ключищи авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау
«ӘЙЕ» «ЮК»

5. Халык җыеннарын үткәрергә:
1 этап: Ключищи авылының Колхоз урамы буенча 95 нче йорт янында (кибет бинасы)
2 этап: Ключищи авылының Үзәк урамы буенча 23А номерлы йорт янында (кибет бинасы)

6. Октябрьский авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
7. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов